Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы

КАРАР

«3» декабрь 2021 ел № 58

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы карары белән расланган муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 45 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга гомуми таләпләр турында федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.».

1.2. Нигезләмәнең 4.2 - 4.6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 29.09.2021 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга гомуми

таләпләр турында федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда шикаятьләр бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый.».

2.2. Нигезләмәнең 4.2 - 4.6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районының
Нурлат шәһәре Советы Рәисе А.С. Әхметшин